әйтеп башкарыла, икенче вариантта мулла бабай чакырыла, ул ясин һәм тәбәрәк укый һәм бу эш мулла белән берлектә эшләнелә.

Татар халкының мал тотуга бәйле бик үзенчәлекле иҗат үрнәкләрен карап үткәнебезчә, ислам дине йогынтысында шактый үзгәреш кичерсә дә халкыбыз бик борынгыдан килгән йола-гадәтләрен, ышануларын саклап килә.

**Литература**

Мустафина, Р.М. Представления, культы, обряды у казахов / Р.М. Мустафина. – Алма-Ата, 1992. – 176 с.

Мустафина, Р.М. Традиции почитания святых у казахов, образы которых связаны с официальной исламской традицией / Р.М. Мустафина // Вестник КазНУ. Сер. Востоковедение. – 2008. №3. – С. 31-37.

Fleur, F. Gilemshin, Fanzilya H. Zavgarova, Alsou D. Battalova. Motives of iIslamic culture in tatar folk tales// The Social Sciences. – 2015. – 10(7): 2081-2084.

http://religiocivilis.ru/islam/456-narodnyi-islam.html.

***Батталова Лилия Муллаҗановна***

Казан (Идел буе) федераль университеты, Казан

## РУС МӘКТӘПЛӘРЕНЕҢ ТАТАР ТӨРКЕМЕНДӘ ГАДИ ҖӨМЛӘ ТЕМАСЫН ӨЙРӘНГӘНДӘ ИНФОРМАЦИОН ТЕХНОЛОГИЯЛӘР КУЛЛАНУ

*Компьютер является одним из важных и новых средств в учебном процессе. Использование его способствовало появлению новых информационных технологий. Компьютерные технологии позволяют реализовать основные методы обучения татарскому языку.*

**Ключевые слова**: *компьютер, технологии, процесс, учеба, методы.*

*The computer is one of the most important and new means in learning process. The use of it has contributed to the emergence of new information technologies. Computer technologies allow to realize the basic methods of learning of the Tatar language.*

**Key words:** *Computer, technology, process, learning, methods.*

Бүген педагогика фәнендә һәм укыту-тәрбия процессында зур үсеш-үзгәрешләр бара. Белем эчтәлеге яңа күнекмәләр белән баетыла, мәгълүмат белән эш итү сәләте үстерелә, шәхесне рухи яктан тәрбияләүгә, кешенең әхлакый йөзен формалаштыруга зур әһәмият бирелә. Ә татар теле укытучысы алдында татар телен камил белгән, татар халкының милли традицияләрен таныган, хөрмәт иткән, аны үстерүгә әзер булган балалар тәрбияләү бурычы өстәлә. Әлеге максатка ирешүдә татар теле һәм әдәбияты укытучылары дәресләрдә заманча укыту технологияләреннән файдаланырга тиеш булалар. Алар арасында елдан-ел уңышлырак кулланылганы, һичшиксез, мәгълүмати технологияләр булыр, дип исәплим.

Белем һәм тәрбия бирүдә мәгълүмати технологияләрнең өстенлекле яклары күп. Беренчедән, дәрес материалын мультимедиа мөмкинлекләргә ия булган югары сыйфатлы күрсәтмәлелек ярдәмендә җиткерү аң үсешенә уңай тәэсир итә. Икенчедән, хәтерләү сәләтен, укучының шәхси сыйфатларын үстерүгә, шулай ук укытуны интенсивлаштыруга ярдәм итә. Төрле дәресләрнең үзара бәйләнешен булдырып, укыту формаларын һәм ысулларын төрләндерү аркасында, дәресләрнең эчтәлеге байый, кызыклырак була. Контроль һәм үзконтроль дәрәҗәсен күтәрергә мөмкинлекләр арта, чөнки материалны кабат укып, хатаны шунда ук төзәтергә, проблема чишүнең берничә вариантын файдаланып карарга була. Укучыларның теманы үзләштерү дәрәҗәсен тикшерү, белемнәрен бәяләү, хаталарын ачыклау, аларны анализлау һәм төзәтү юлларын билгеләү өчен компьютер технологияләре уңайлы. Укыту процессында алгы педагогик технологияләрне куллану яңа метод-алымнарны үстереп укытытучыларга, эш стилен үзгәртеп, яңача укытырга, педагогик системада структур үзгәртеп коруларны гамәлгә ашырырга ярдәм итә. Бу исә педагогик процессны оештыруга һәм аның белән идарә итүгә үзенчәлекле бурычлар куя. Шулай итеп, татар телен инновацион технологияләр белән укыту-уку процессын яңача оештыру дигән сүз. Аның мөһим мәсьәләләре булып өйрәнелә торган фәнгә кызыксыну уяту, танып-белү активлыгын үстерү, аралашу процессында үзара аңлашу һәм ярдәмләшү мохите тудыру, укучыларның иҗади сәләтләрен ачыклау һәм үстерү тора.

Бүгенге көндә инновацион технологияләр кулланмаган укытучы юктыр. Мин үземдә татар теле дәресендә еш кына компьютер технологиясе кулланам. Татар теле дәресендә гади җөмлә синтаксисы бүлеген өйрәнгәндә интерактив тактада төрле авырлыктагы тестлар кулланам. Мондый тестлар – контроль ясаучы.

**Гади җөмлә синтаксисы**

1.Синтаксисның төп берәмлекләре:
а) сүзтезмә һәм җөмлә
ә) сүз һәм сүзтезмә
2.Бер генә өлештән торган җөмлә нинди җөмлә була?
а) кушма җөмлә
ә) гади җөмлә
3.Түбәндә язылган сүзләр нәрсәләр?
***Зәңгәр күлмәк, стена сәгате, сыек томан.***
а) сүзләр
ә) җөмләләр
б) сүзтезмәләр
4.Сүзтезмә нинди кисәкләрдән тора?
а) ияртүче һәм ияручe
ә) тезүле һәм иятүле
5.Сүзтезмә ничә төркемчәгә бүленә?

а) 5
ә) 6
б) 4

Әлеге тестларны үткән темаларга яраклаштырып укытучы да үзе төзи ала. Ә инде укучыларга дифференциаль өй эше биргәндә тест төзеп килергә кушсаң, күп кенә укучылар моны зур теләк белән башкаралар. Мондый тестларны без укучылар белән аерым папкаларга туплап барабыз. Татар теленнән шулай ук электрон дәреслекләребез бар. Шулай ук андагы элементларны дәресләрдә кулланау интерактив такта ярдәмендә дәресне кызыклы һәм мавыктыргыч итеп үткәреп була. Шулай ук компьютер технологияләре формаларының берсе – мультимедияле рефератлар һәм презентацияләр. Мультимедияле презентацияләрнең максаты – мәгълүматны күрсәтмәле, җиңел үзләштерелә торган формада бирү. Әлеге презентациярне әдәбият дәресләрендә файдалану нәтиҗәле. Чөнки мультимедияле презентацияләр ярдәмендә язучыларның тормыш юлын сөйләп, күрсәтеп була; әдәби әсәрне анализлаганда мөһим пунктларны бирү өчен кулланырга мөмкин. Ә татар теле дәресләрендә әлеге презентацияләр плакат, схемаларны алыштыра ала.

Минемчә, без, татар теле һәм әдәбияты укытучылары буларак, иң беренче чиратта, халыкның милләт буларак асылын, тарихын, тормыш-көнкүрешен, гореф-гадәтләрен чагылдырган терминнарга, сүзләргә һәм төшенчәләргә игътибар итәргә яки тел, әдәбият һәм мәдәният бәйләнешләрен күрсәтергә тиешбез. Менә шушы эшләрне без төрле технологияләр ярдәмендә башкарсак, аларны аңлатсак, бигрәк тә, уңышлы булыр иде дип саныйм. Компьютер технологияләреннән уңышлы файдалану, тел һәм әдәбият фәненә иҗади якын килеп эшләү зур нәтиҗәләргә ирешергә ярдәм итә. Укучыларда ана телебезгә карата мәхәббәт тәрбияли, аның байлыгын, матурлыгын, фикер тирәнлеген ачып бирә, аны мәдәниятле итә, һәрьяклап үстерә, шәхес итеп тәрбияли. Укытучы укучыга тормышта үз урынын табарга ярдәм итүче төп ышанычы булып кала. Соңгы өч елда татар теле дәресләрен компьютерлы дәреслек һәм китапларны кулланудан башка күз алдына китереп булмый. Шуңа күрә укытучы укучының тормышта үз урынын табарга ярдәм итүче төп ышанычы булып кала да инде.

**Әдәбият**

1. Гыймадиева, Н. Дәрестә һәм дәрестән соң / Н. Гыймадиева. – Казан: «Яңалиф» нәшрият йорты, 2004.
2. Мукимова, Н. Милли-мәдәни шартларда тел өйрәнү. – Мәгариф. – 2010. – №9.
3. Низамов, А.М. Тәрбия нигезләре / А.М. Низамов. – Казан:«Мәгариф», 2005. – 335 б.
4. Сафиуллина, Ф.С. Татар теленә өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре / Ф.С. Сафиуллина. – Казан: «Хәтер» нәшрияты, 2001. – 432 б.